ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЕЛАБУЖСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫАЛАБУГА
МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** 25.02.2026 290 **КАРАР**

Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «2026 елга Алабуга муниципаль районының муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында укучыларның туклануын тәэмин итү турында» 2026 елның 21 гыйнварындагы 47 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы (ЭЭМ) коллегиясенең 2022 елның 11 февралендәге ПР-27 номерлы киңәйтелгән утырышы һәм Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгы (ЭЭМ) коллегиясенең 2022 елның 14 февралендәге МК 1 номерлы киңәйтелгән утырышы йомгаклары буенча Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов йөкләмәләрен, шулай ук «Гомуми белем бирү учреждениеләрендә, башлангыч һәм урта һөнәри белем бирү учреждениеләрендә укучыларны тукландыруны оештыруга Санитар - эпидемиологик таләпләр» СанПиНның 2.3/2.4.3590-20 номерлы балаларны социаль яклау, аларның сәламәтлеген ныгыту, белем бирү учреждениеләрендә укучыларны балансланган кайнар аш белән тәэмин итү нормаларын үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының 2026 елның 21 гыйнварындагы 47 номерлы карары белщн расланган Алабуга муниципаль районының муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында укучыларның туклануын оештыруны тәэмин итү тәртибе турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 2 бүлегенең 2.4 пунктындагы 5 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- озайтылган көн төркемнәрендә укучыларны тукландыруның уртача бәясе ата-аналар акчалары исәбеннән көнгә 66 сум 70 тиен тәшкил итә. «Россия Федерациясе милли гвардиясе гаскәрләренең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча ведомстводан тыш саклау идарәсе» федераль дәүләт казна учреждениесе филиалының-Алабуга районы буенча ведомстводан тыш сак бүлеге һәм Эчке эшләр

министрлыгының Алабуга районы буенча бүлеге хезмәткәрләренең балалары өчен 50% (проценты) күләмендә ташламалар бирелми. Туклану бәясе шәһәр, шулай ук авыл мәктәпләрендә укучылар өчен бертөрле;».

1.2. Нигезләмәнең 2 бүлегенең 2.8 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.8. «Россия Федерациясе милли гвардиясе гаскәрләренең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча ведомстводан тыш саклау идарәсе» федераль дәүләт казна учреждениесе филиалының - Алабуга районы буенча ведомстводан тыш сак бүлеге һәм Эчке эшләр министрлыгының Алабуга районы буенча бүлеге хезмәткәрләренең 5-11 сыйныфларда укучы балалары өчен көненә бер укучыга кайнар туклануның уртача бәясенең 50% (проценты) күләмендә, дип билгеләргә.

Ташлама «Россия Федерациясе милли гвардиясе гаскәрләренең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча ведомстводан тыш саклау идарәсе» федераль дәүләт казна учреждениесе филиалының - Алабуга районы буенча ведомстводан тыш сак бүлеге һәм Эчке эшләр министрлыгының Алабуга районы буенча бүлеге тарафыннан агымдагы айның 10 числосына кадәр аө саен Алабуга муниципаль районының гомуми белем бирү учреждениесе җитәкчесенә җибәрелә торган хезмәткәрләр реестрлары нигезендә бирелә».

1.3. Нигезләмәнең 3 бүлегенең 3.3.3 пунктындагы 11 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«в) ата-аналары, «Россия Федерациясе милли гвардиясе гаскәрләренең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча ведомстводан тыш саклау идарәсе» федераль дәүләт казна учреждениесе филиалының - Алабуга районы буенча ведомстводан тыш сак бүлеге һәм Эчке эшләр министрлыгының Алабуга районы буенча бүлеге хезмәткәрләре булган балалар өчен»:».

2. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль үсеш буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче

ДОКУМЕНТ ПОДПИСАН ЭЛЕКТРОННОЙ ПОДПИСЬЮ

СВЕДЕНИЯ О СЕРТИФИКАТЕ ЭП

Сертификат: 2AE1AA8E107BD0A6911BA308E44A8D0A
Владелец: Ахмадеева Эльмира Равильевна
Действителен с 28.01.2025 до 23.04.2026

Р.Э. Әхмәдиева

Лист согласования к документу № 290 от 25.02.2026
Инициатор согласования: Половинкина И.А. Главный специалист
Согласование инициировано: 25.02.2026 11:31

**Лист согласования** Тип согласования: **последовательное**

| N° | ФИО | Срок согласования | Результат согласования | Замечания |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Ахмадеева Э.Р. | | Подписано 25.02.2026 - 11:44 | - |